**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2020 ел, 25 май N181

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәнең кайбер пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законына таянып Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Бакырчы авыл җирлеге советының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 162 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең түбәндәге пунктларының гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга:

- 15 статьяның 2 пункты;
- 15 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 3 пункты;
- 27 статьяның 4 пункты.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бакырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Бакырчы авыл**
**җирлеге Башлыгы** **Ф.Х. Вәлиев**